ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

17 декабрь, 2015 ел № 4/10

Шәһәр Советының 2008 елның 18 апрелендәге 31/10 санлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәренең җирле үзидарә органнарында, муниципаль органында командировкага җибәрү тәртибе турында Нигезнамәгә үзгәрешләр кертү хакында

РФ Президентының 2015 елның 30 сентябрендәге «Россия Федерациясе Президентының 2005 елның 18 июлендәге 813 санлы Указы белән расланган федераль дәүләт граждан хезмәткәрләрен командировкага җибәрү тәртибенә һәм шартларына үзгәрешләр кертү турында» 492 санлы Указы, ТР Президентының 2005 елның 9 сентябрендәге «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен командировкага җибәрү тәртибе һәм шартлары турында» УП-366 санлы Указы, шәһәр Уставының 28 маддәсе нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2008 елның 18 апрелендәге «Яр Чаллы шәһәренең җирле үзидарә органнарында, муниципаль органында командировкага җибәрү тәртибе турында Нигезнамәне раслау хакында» 31/10 санлы Карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1) 6,7 пунктлары үз көчен югалткан дип танырга;

2) 8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Хезмәткәрнең хезмәт командировкасында булу вакыты (командировкага җибәрлегән урынга килү датасы һәм аннан китү датасы) җирле үзидарә органына, муниципаль органга хезмәт командировкасыннан кайткач тапшырылган юл документлары (билетлары) буенча билгеләнә.

Юл документлары (билетлары) булмаган очракта, хезмәткәрнең хезмәт командировкасында булуының факттагы вакыты федераль дәүләт граждан хезмәткәрләре өчен билгеләнгән исемлектә каралган, хезмәт

командировкасында булу чорын раслаучы башка документлар буенча билгеләнә.»;

3) 9 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

4) 15 пунктта:

- «түләнә» сүзен «кайтарыла» сүзенә алыштырырга;

- «шулай ук көннәр» сүзләрен «шулай ук көннәр өчен» сүзләренә алыштырырга;

5) 19 пунктта «пассажирларны транспортта мәҗбүри шәхси иминиятләштерүгә иминиятләштерү түләве» сүзләрен төшереп калдырырга;

6) түбәндәге эчтәлектәге 19.1 пунктын өстәргә:

«19.1 Хезмәткәр командировкага җибәрелгән урынга бару өчен һәм (яки) кирегә – муниципаль хезмәтне үтүнең даими урынына кайту өчен һава транспортыннан файдаланганда, юл документлары (билетлары) бары тик Россия аиакомпанияләре яки башка дәүләтләр – Евразия икътисадый союзы әгъзалары авиакомпанияләре рейсларына рәсмиләштерелә (сатып алына), күрсәтелгән авиакомпанияләр хезмәткәр командировкага җибәрелгән урынга пассажирлар йөртүне башкармаган яисә әлеге авиакомпанияләрнең рейсларына хезмәткәрнең барлык командировка вакытына юл документларының (билетларның) булмавы аркасында, юл документларын (билетларны) рәсмиләштерергә (сатып алрыга) мөмкин булмаган очраклардан тыш.»;

7) 21 пунктта беренче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«21. Юл документлары (билетлары) яки транспорт оешмалары тарафыннан бирелгән һәм юл докуменларындагы (билетлардагы) мәгълүматны раслаучы документлар булмаганда, юл хакы түләнми.»;

8) 24 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

9) 25 пунктта «Россия Федерациясендә билгеләнгән» сүзләрен «Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгә» сүзләренә алыштырырга;

10) 28 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« 28. Хезмәткәрне хезмәт командировкасына хөкүмәтара килешүләр төзелгән дәүләтләр – Бәйсез Дәүләтләр Бердәмлегендә катнашучылар территориясенә җибәргәндә, керү һәм чыгу документларына чик буе органнары тарафыннан дәүләт чиген үтеп чыгу турында билге куелмый, Россия Федерациясе дәүләт чиген үтеп чыгу датасы юл документлары (билетлары) буенча билгеләнә.»;

11) 34 пунктның «а» пунктчасында «тиешенчә рәсмиләштерелгән командировка таныклыгы» сүзләрен һәм «пассажирларны транспортта мәҗбүри шәхси иминиятләштерүгә иминиятләштерү түләве,» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев